ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРЫССУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАР

№ 21 Иске Урыссу ав. 26 сентябрь 2023 ел

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлеге Советының 2023 елның 1 мартындагы 2 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

2007 елның 2 мартындагы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында»гы 25-ФЗ санлы Федераль законга, 2008 елның 25 декабрендәге «Коррупциягә каршы тору турында»гы 273-ФЗ санлы Федераль законга, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законга, 2023 елның 10 июлендәге '' Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында"гы 286-ФЗ санлы Федераль законга ярашлы, 2013 елның 23 июнендәге «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы»ның 50-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы законы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Нигезләмәнең 8 пунктының 8.7 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «мәнфәгатьләр конфликты ягы булган муниципаль хезмәткәрләрнең мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу буенча чаралар күрмәве, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәттән азат итүгә китерә торган хокук бозу булып тора».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталын «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://jutaza.tatarstan.ru/.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Урыссу авыл җирлеге башлыгы Ф.Г.Әминова